**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**«27» июнь 2019 ел** **№47/1**

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
«Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының
2018 елның 14 сентябрендәге 38/3 санлы карары белән расланган
«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл
җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын
үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 маендагы 87-ФЗ санлы Федераль законның 1 маддәсе 13 пункты «б» пунктчасы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына таянып, Иштирәк авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 14 сентябрендәге 38/3 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге нигезләмәнең 3.5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Гражданнар җыены торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия булган яртысыннан артыгы катнашканда хокуклы. Әгәр торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган яртысыннан артыгы бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, гражданнар җыены күрсәтелгән торак пункт кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгәннән соң бер айдан да артмаган срокта этаплап үткәрелә. Шул ук вакытта гражданнар җыенында элегрәк катнашкан затлар тавыш бирүнең алдагы этапларында катнашмый. Әгәр гражданнар җыены карары өчен гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, ул кабул ителгән дип санала.»

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Иштирәк авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халыкның куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе Г.С. Гарифуллина